# Тамчы

**«2нче санлы Җәлил мәктәбе»нең газетасы.**

СЕНТЯБРЬ **№2** (46) 2015-2016 уку елы

**7 сентябрь — 14 сентябрь**

Ел саен мәктәп газетасы үзгәреп тора — форматы, дизайны, редколлегиясе белән. 2015-2016 уку елы да искәрмә түгел. Безнең командага хәзер бик күп тир түгәргә туры киләчәк, чөнки «Тамчы» айга 1 түгел, ә 4 тапкыр чыгачак (!).

Горур вә мәһабәт Татарстанның ике дәүләт телен хөрмәтләү, мәктәбебезнең укытучылары һәм укучыларына махсус мәйдан булдыру — безнең максатыбыз шундый. Хәер, быелгы «искене», ягъни 2014-2015нче уку елының төп газета традицияләрен бозмаска тырышырбыз. Иҗат, һичшиксез, һәрвакыт алгы планда!

Кадерле укучылар! Безнең мәктәбебезгә быел 45 яшь!! Бүлеп карасак, 4 һәм 5 саннары килеп чыга. Сез дә шул «саннарга» гына укыгыз! Иҗат итегез! Мәктәп елларыннан ләззәт алыгыз! :) Идеяләрегез булса, тагын да яхшырак — «Тамчы» уй-фикерләрегезне хуплаячак.

Сезгә уңышлар теләп, *Резидә Әлмиева*

## АКТУАЛЬ яңалыклар



**Мәктәп «Игелекле Татарстан» акциясендә катнаша** — 7нче сентябрьдән 14нче сентябрьгә кадәр һәр көн берәр нинди изге темага багышлана. Беренче көндә — «Яхшы сүз көне»ндә дежур класс укучылары бар укучыларны «Яхшылык атнасы»ның эмблемасы — смайликлар белән каршылады. Шулай ук көнләп «Спортив Татарстан», «Сәламәт Татарстан» һәм башкалар алып барылды. Акция вакытында класс сәгатьләре, класстан тыш дәресләр үткәрелде.

**БУ АТНАДА НИЛӘР БУЛДЫ?** КЫСКАЧА:

АТНА ТӨРЛЕ РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ АКЦИЯ ҺӘМ ЧАРАЛАРГА БАЙ БУЛДЫ: «Игелекле Татарстан», «Яхшы сүз», «Аеклык бәйрәме» чараларында укучылар актив катнашты.

1. «Аеклык бәйрәме»ндә 6нчы сыйныфлар арасында зарядка оештырылды.
2. Мәктәп парламенты үз эшен башлады. Класс сәгатьләре, класстан тыш дәресләр булып узды.
3. 8-9 класслар арасында президентлар күрсәтелде. Икенче атнага алар үзләрен күрсәтү мөмкинлегенә ия булачак. **«Тамчы» сезне киләчәк президентлар белән таныштарачак!**





**Быелгы уку елын Җәлил бистәсендәге 2 нче урта мәктәп 45 еллык юбилеен билгеләп каршылый.** Аның беренче директоры булган Җәмил Газиз улы Нигъмәтовның тәүге педагогик киңәшмәдә әйтелгән: <u>“Укучы - ул</u>




<u>белем белән тутырылырга тиешле савыт түгел, ә яндырып җибәрелергә тиеш учак, очкын. Ә аны үзең дөрләп янганда гына яндырып була</u>” сүзләре бүген дә әлеге зур коллективның хезмәт девизы, төп чакыруы булып яши. Нәкъ элеккеге кебек үк мәгарифтәге үзгәрешләргә, яңалыкка йөз белән борылырга әзер, укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә нәтиҗәле алымнарны өйрәнүгә омтылыш белән яши торган мөгаллимнәрне берләштерә белем учагы. Үзенең үткәненә хөрмәт, киләчәккә ныклы ышаныч һәм сүнмәс хезмәт дәрте белән яши.

Җәмил Газиз улы белән мәктәпнең беренче еллары бәйләнсә, коллектив белән җитәкчелек итәргә алынган Юрий Иванович Горшков исеме белән мәктәпнең кабинет системасына күчеп укытуы бәйле. Моның өчен бер төркем укытучылар Түбән Кама шәһәрендәге 6,7 санлы мәктәпләргә юнәлә. Белем бирүдә яңа мөмкинлекләр ачкан кабинет системасы укытучыларга канат куеп кайтаргандай була. <u>1973 елда мәктәбебез районда беренчеләрдән булып әлеге яңалыкны кулланырга тотына.</u>

1976 елдан мәктәп белән Риф Мәхмүт улы Мәхмүтов җитәкчелек итә. 1977 елда мәктәпнең методик бүлмәсе республикакүләм конкурста 1нче урынны яулый. <u>Мәктәп зур телевизор, ә кабинет җитәкчесе сәяхәткә юллама белән бүләкләнә.</u> 1980 елда мәктәпнең “Ал җилкәннәр” дип аталучы агитбригадасы зур җиңүгә ирешә.

Аннан Ә.К.Әлимов җитәкчелегендә спортчылар, М. Х. Шаммасов җитәкләгән “Авиамоделистлар” түгәрәге әгъзалары, 1980 елда китапханәче М.Ш. Юзлибаева укучылары...

**Ландыш ШӘЙДУЛЛИНА**

*(дәвамы икенче биттә)*

# «4ле, 5ле» юбилей

Уңышларны санап чыгу, аларны барлау авыр эш түгел, ләкин һәрбер җиңүнең нинди көч сораганын, аның даими хезмәт нәтиҗәсе булуын һәркем аңлый, тоемлый. Ул элек тә шулай булган, хәзер дә. Уңышка ирешү бер дә җиңел бирелми бит ул. Матур күрсәткечләр артында укытучылар һәм укучыларның бердәм эшчәнлеге, фидакарь хезмәте тора. Мәктәбебез һәрвакыт үзенең әнә шундый мөгаллимнәре белән горурланды һәм горурлана. Без зур хөрмәт белән остаз укытучыларыбызны искә алабыз. Алар үзләренең шәхси үрнәкләре белән дә, тәҗрибәләрен уртаклашулары белән дә коллективның яңа үрләр яулавына, матур традицияләрне саклый алуыбызга нигез булдырдылар. Шуңа да мәктәптә дистәләрчә еллар хезмәт куйган мөгаллимнәребез, әле генә килеп эшли башлаган яшьрәк буын вәкилләренең һәркайсысы турында иркенләп сөйләп була бүген. Ә менә мәктәптәге методик эшчәнлекнең йөрәге, идеяләр генераторы булган бистәнең почетлы кешесе, халык мәгарифе отличнигы Л. В. Маркова исә бүген дә сокландыра, аның яшәү дәртенә, иҗади ялкынына, хәтеренә, активлыгына көнләшми мөмкин түгел. Ул мәктәбебезнең тарихын булдыруда, буыннар чылбырын саклап яшәүдә зур терәк, безнең барыбыз өчен яшәү үрнәге, чын укытучы эталоны булып тора.

1990 елдан мәктәпне Любовь Александровна Шаронова җитәкли башлый һәм мәктәп сәхифәләре тагын матур күрсәткечләр белән баетыла. Бөтен көчен мәгариф өлкәсенә биргән мөгаллимәгә 1997 елда Татарстанның атказанган укытучысы исеме бирелә, ул бистәбезнең иң абруйлы кешеләренең берсенә әверелә.

2002 елдан районда иң зур белем йортының тарихы Сорос премиясе лауреаты, 44 еллык мөгаллимлек тәҗрибәсе булган Р.Г.Хәбибуллин исеме белән бәйле. Ул җитәкчелек иткән чорда үткәрелгән капиталь төзекләндерүләрдән соң мәктәбебез ерактан ук балкып, нур биреп торадыр кебек. Аның матди-техник базасы баетылды, мәктәп яңы территориясе, кабинетлар, коридорлар, гомумән барлык бүлмәләрнең бизәлеше яңа төсмер алды, алар матурлыкны күрә белергә өйрәтәләр, аны булдыру теләге уяталар.

Ул укытучылар һәм укучыларны бер бердәм командага туплый алды. Шуның нәтиҗәсе буларак, мәктәп фәнни бәйгеләрдә, спорт ярышларында, мәдәни чараларда бик матур нәтиҗәләргә ирешә, гел алдынгы урыннарга лаек булды.

Юбилейлар, узган эшләргә нәтиҗә ясап, яңа үрләрне яулау өчен стимул бирә. Коллективыбыз, өлкән буын педагоглар башлаган уңай традицияләрне кулланып, заман таләпләре югарылыгында белем һәм тәрбия бирә. Менә шушы юлдан тайпылмыйча, сынатмыйча эшләргә язсын иде. **Бәйрәм белән, хөрмәтле хезмәттәшләр.**



*Ландыш ШӘЙДУЛЛИНА,*
*профком җитәкчесе*



«Сәләт» оешмасының «Болгар Туган Тел» форумында быел Резедә Афзалова һәм Эльвина Фәттахованың ял итеп кайтты. Без аларның әйдаманы белән элемтәгә кердек.

**Алсу АЙЗЯТОВА, әйдаман:** "Болгар Туган Тел"дә икенче тапкыр әйдаман булсам да, мондa килгән балаларга сокланып туя алмыйм! Актив, сәләтле, ачык йөзле, киң күңелле, максатчан, күзләреннән очкын чәчрәп тора аларның. Җәлилдән Эльвина белән Резеда да шундыйлардан. Беренче көннән үк үзләрен бары яхшы яктан гына күрсәттеләр алар. Концертка номер куюдисеңме, плакатлар әзерләү дисеңме - барысында да алдынгы булдылар:) Резеда - актриса, Эльвина - иң ягымлы кызларның берсе, икесе дә тик тора торганнардан түгел! Аларнын икесенең дә җаваплы кызлар икәнен дә ассызыклап китмичә булмый, ни кушсаң, шуны жиренә җиткереп эшлиләр. Смена дәверендә төркемнең алыштыргысыз сәлкешләре булдылар. Күңелемдә бары җылы хатирәләр калдырган, йөрәгем түрендә урын алган Резедам белән Эльвинамны киләсе елга да «Болгар Туган тел»дә көтеп калам!

## Фильм: яратам, киңәш итәм!

Бу атнаның сишәмбе көнендә безне — 7-8нче сыйныф укучыларын — кинотеатрга алып бардылар. Бирөдә без «Чужая мать» фильмын карадык. Фильм наркомания һәм башка дөнья «чирләре»ннән сак булырга киңәш итә.

Гыйбрәт, укучыларга сабак булырдай итеп рекомендация бирделәр безгә, ә чынлыкта… «мәктәп халкы» җитди әйберләрдән көлде, фильм беткәч ошамады, дип йөрде.

Уйландыра бу хәлләр… Ә менә укытучылар ничек уйлый икән? Нинди фильм карарга кирәк безгә? Үзләре кайсыларын ярата? Хәбәрчебез Нәргизә инде барысын да эшләп куйды!

**Эдуард Рәфисович**: яраткан фильмы — «Легенда №17», укучыларга — «Слава».
**Руслан Шәукәтович**: яратканы — «Гангстеры», укучыларга — «Легенда №17»
**Айгөл Робертовна**: яратканы — «17 мгновений весны», тәкъдим итә — «Каникулы строгого режима»
**Айдар Илдарович**: ярата «Великий Гэтсби»ны, тәкъдим итә — «Волк с Уолл-Стрит»
**Ләйсән Равилевна**: «Гарри Поттер» (бар кисәкләрен)
**Әлфинур Флеровна**: «Красотка»
**Гөлнур Рәисовна**: «Ключ без права», «Красотка».

*Текст: Р. Әлмиева, сораштыру — Н. Биккулова*

**Шеф редактор**: Шәйдуллина Ландыш Камил кызы
**Редколлегия**: Ихсанова Ләйсән (11А), Әлмиева Резидә, Гарифуллина Әдилә, Гыйлфанова Раилә, Шаәйдуллина Айгөл, Шәйхрамов Ленар (8 кл).
**Материалны редколлегия әгъзалары һәм шеф-редактор (307 каб.) кабул итә.**